# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

"Татарстан Республикасында юллар фонды турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

"Татарстан Республикасында юллар фонды турында" Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы Югары Советы җыелма басмасы, 1992 ел, N 3; 1993 ел, N 3; 1994 ел, N1-2 ) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

<u>1 статья.</u> 1 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә;

"3. Татарстан Республикасы юллар фондының акчалары республика территориясе чикләрендәге гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын һәм бакчачылык, яшелчәчелек ширкәтләренә илтә торган автомобиль юлларын тотуны, ремонтлауны, реконструкцияләүне һәм төзүне финанслау өчен, шулай ук юл хуҗалыкларына идарә итү буенча чыгымнарны, җитештерү базаларын киңәйтү, техника сатып алу өчен чыгымнарны капларга юнәлтелә".

<u>2 статья.</u> 4 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"<u>4 статья.</u> Ягулык-майлау материалларын сатуга салым

Ягулык-майлау материалларын (автомобиль бензинын, дизель ягулыгын, майларны, мотор ягулыгы сыйфатында кулланылучы кысылган һәм сыекландырылган газны) сатуга салым, милек рәвешләренә, кайсы ведомствога буйсынуларына һәм оештыру-хокукый рәвешләренә карамастан, предприятиеләр, берләшмәләр, оешмалар, учреждениеләр һәм хуҗалык итүче башка субъектлар өчен сату бәясенең (акчалата хисапта) 35 проценты күләмендә, өстәлгән бәяләргә салымнан һәм махсус салымнан гайре, билгеләнә.

Предприятиеләр, берләшмәләр, оешмалар, учреждениеләр һәм

хуҗалык итүче башка субъектлар алып саткан вакытта салым ягулык-майлау материалларын сатудан килгән табыш белән (өстәлгән бәяләргә салымнан һәм махсус салымнан гайре) аларны сатып алу бәясе (өстәлгән бәяләргә салымнан һәм махсус салымнан гайре) арасындагы аерма күләменнән билгеләнгән ставка буенча исәпләнелә".

<u>3 статья.</u> 5 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3. Салым түләүдән түбәндәгеләр азат ителә:

колхозлар, совхозлар, крестьян (фермер) хуҗалыклары һәм аларның берләшмәләре, авыл хуҗалыгы продукцияләрен җитештерү белән шөгыльләнүче һәм бу продукцияләрне сатудан килгән керемнәрнең чагыштырма күләме барлык салымнар суммасыннан 70 процент һәм аннан да күбрәк процент тәшкил итүче акционер һәм башка предприятиеләре;

тулысынча дәүләт бюджеты исәбенә тотылучы учреждениеләр;

психик авыруларны дәвалау һәм реабилитацияләү белән шөгыльләнүче дәүләт дәвалау учреждениеләре каршындагы дәвалау-җитештерү дәүләт предприятиеләре;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һәм Бөтенроссия чукраклар җәмгыяте (ВОГ), Бөтенроссия сукырлар җәмгыяте (ВОС), Бөтенроссия гариплләр җәмгыяте (ВОИ) балансындагы предприятиеләр;

яшелчә, җиләк-җимеш үстерүче бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләре".

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1995 елның 12 июле
N 196